**ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

26.09.2013 | Казан ш. | № 5-20/э

***«Теплоснабсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә тарифлар билгеләү хакында***

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә электр һәм җылылык энергиясенә карата бәя кую турында» 2004 елның 26 февралендәге 109 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Теплоснабсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә шушы карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы
Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
26.09.2013 № 5-20/э
карарына кушымта

## «Теплоснабсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә тарифлар

| Тәртип саны | Муниципаль берәмлек, җылылык белән тәэмин итүче оешма, кулланучылар категориясе исеме | Җылылык энергиясенә тариф | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кайнар су | басым астында сайланма пар | | | | кискен һәм редукцияләнгән пар пар |
| | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см$^2$ кадәр | 13,0 кг/см$^2$ югары | |
| | Казан шәһәре | | | | | | |
| 1 | «Теплоснабсервис» ЖЧЖ | | | | | | |
| 1.1 | Җылылык энергиясен җитештерү һәм тапшыру өчен түләүче кулланучылар (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча): | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 1207,14 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә): | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 1424,43 | - | - | - | - | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча
дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту
һәм теркәү бүлеге